| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>**05.08.2024** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 414** |

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмә нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен 1- 12 нче кушымталарда каралганча кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына әлеге карарга 1 нче - 12 нче кушымталарында күрсәтелгән шәһәр һәм авыл җирлекләре Башкарма комитетлары белән килешү төзергә.

3.Әлеге карарның 1 пункты нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларыннан Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган финанс чаралары исәбеннән башкарыла, шулай ук «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Зеленодольск муниципаль районы Советы карарында каралган очракларда һәм тәртиптә үз матди ресурсларыннан һәм финанс чараларыннан өстәмә файдаланырга хокуклы.

4. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының түбәндәге карарлары үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында » 2023 елның 20 июлендәге 299 номерлы;

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының «Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында » 2023 елның 20 июлендәге 299 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 7 сентябрендәге 315 номерлы;

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының «Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында » 2023 елның 20 июлендәге 299 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 октябрендәге 325 номерлы (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2023 елның 7 сентябрендәге 315 номерлы карарына кертелгән үзгәрешләре белән).

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советының «Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча Зеленодольск муниципаль районы составына керүче шәһәр һәм авыл җирлекләре вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында » 2023 елның 20 июлендәге 299 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 28 декабрендәге 361 номерлы (Зеленодольск муниципаль районы Советының 2023 елның 7 сентябрендәге 315 номерлы, 2023 елның 2 октябрендәге 325 номерлы карарларына кертелгән үзгәрешләре белән).

5. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы , Советы рәисе** **М. П. Афанасьев**

Зеленодольск муниципаль районы
Советының 2024 елның 5 августындагы
414 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге үзенең вәкаләтләренең түбәндәге бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыра:**

- «Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә чокырларга ремонт ясау.
- Октябрь п. тимер юл янындагы юл буенда тротуар салу.

Зеленодольск муниципаль
районы Советының
2024 елның 5 августындагы
414 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге мәсьәләсе буенча үзенең вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыра:**

- «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә чокырларны ремонтлауны.
- «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Ленин урамында тукталыш кесәсе урнаштыру.
- «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә яңа юл билгеләре урнаштыру.
- «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә юл тамгалары салу
- «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Мәктәп урамында тротуарда су агызу лотогын урнаштыру
- «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Стахановская урамында ясалма юл тигезсезлеген кую.
- «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Спорт урамында ясалма юл тигезсезлеген кую.
- «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Вокзааал алды урамында ясалма юл тигезсезлеген кую.
- «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Карл Маркс урамында ясалма юл тигезсезлеген кую.
- «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә Җиңү урамы буенча 59 нчы йорттан алып 73 нче йортка кадәр юлны ремонтлау.
- «Васильево шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә Куйбышев урамы буенча юлны ремонтлау.

Зеленодольск муниципаль
районы Советының
2024 елның 5 августындагы
414 номерлы карарына
3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге мәсьәләсе буенча үзенең вәкаләтләренең түбәндәге өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыра:**

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә чокырларны ремонтлау.
- Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогының Тынычлык урамы буенча асфальт-бетон өслек салу.
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Исаково авылының Киң һәм Кояшлы урамнары киселешендә яңа юл билгеләрен урнаштыру.
- Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогында «3 км» тимер юл кичүе янында юл билгеләрен урнаштыру.
- Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогының Совет ур., 100 нче йорт буенча ясалма юл тигезсезлеге кую.
- Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогының «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Свияжск(Зөя) урта гомуми белем бирү мәктәбе» МБГБУ янына яңа юл билгеләрен кую.
- Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогында мәктәп автобусы керү өчен өчен мәйданчык төзү.
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең Мизиново авылында балалар мәйданчыгы янына тротуар салу.
- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр тибындагы 51 нче «Тополек» гомумүстерү төрендәге балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесенә керү юлы салу.

Зеленодольск муниципаль
районы Советының
2024 елның 5 августындагы
414 номерлы карарына
4 нче  кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Әйшә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге  җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге мәсьәләсе буенча үзенең  вәкаләтләренең түбәндәге бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыра:**

- «Әйшә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә чокырларга ремонт ясау.
- «Әйшә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Әйшә авылында Юбилей урамыннан алып  Кояшлы урамына кадәр  юл салу.

Зеленодольск муниципаль
районы Советының
2024 елның 5 августындагы
414 номерлы карарына
5 нче  кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керә торган «Осиново шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге мәсьәләсе буенча үзенең вәкаләтләренең түбәндәге бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыра:**

- «Осиново авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә чокырларга ремонт ясау.
- Осиново авылының Гагарин урамында җәяүлеләр кичүе янында яңа тротуар салу.
- Осиново авылында яңа поликлиника янында парковка урнаштыру.
- Осиново авылының  Нагорная урамында яңа поликлиникадан алып борылышка кадәр тротуар ясау.

Зеленодольск муниципаль
районы Советының
2024 елның 5 августындагы
414 номерлы карарына
6 нчы кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Раифа авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге мәсьәләсе буенча үзенең вәкаләтләренең түбәндәге бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыра:**

- «Раифа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бело- Безводное авылы мәктәбенә керү юлын салу.
- «Раифа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бело- Безводное авылы Дуслык урамы буенча юлны ремонтлау.
- «Раифа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Бело- Безводное авылы Яңа урамы буенча юлны ремонтлау.

Зеленодольск муниципаль
районы Советының
2024 елның 5 августындагы
414 номерлы карарына
7 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге мәсьәләсе буенча үзенең вәкаләтләренең түбәндәге бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыра:**

- «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Күгәй авылында тукталыш павильонына мәктәп автобусы килү өчен мәйданчык төзү
- «Күгәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тау Иле авылында мәктәп автобусы маршруты өчен тукталыш урнаштыру.

Зеленодольск муниципаль
районы Советының
2024 елның 5 августындагы
414 номерлы карарына
8 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Большие Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге мәсьәләсе буенча үзенең вәкаләтләренең түбәндәге бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыра:**

- «Большие Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Большие Ключи авылында хастаханәгә керү юлы салу.

Зеленодольск муниципаль
районы Советының
2024 елның 5 августындагы
414 номерлы карарына
9 нчы кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче « Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге мәсьәләсе буенча үзенең вәкаләтләренең түбәндәге бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыра:**

- «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Рус Мари Кавалы авылында Үзәк урамы буенча юл салу.

Зеленодольск муниципаль
районы Советының
2024 елның 5 августындагы
414 номерлы карарына
10 нчы кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге мәсьәләсе буенча үзенең вәкаләтләренең түбәндәге бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыра:**

- «Рус Әҗиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегененңРус Әҗиле авылында мәктәп автобусы маршруты өчен тукталыш урнаштыру.

Зеленодольск муниципаль
районы Советының
2024 елның 5 августындагы
414 номерлы карарына
11 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Акъегет авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге мәсьәләсе буенча үзенең вәкаләтләренең түбәндәге бер өлешен Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыра:**

- «Акъегет авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Сунчәле авылында мәктәп автобусы маршруты өчен тукталыш ясау.

Зеленодольск муниципаль
районы Советының
2024 елның 5 августындагы
414 номерлы карарына
12 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Новопольский» авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге мәсьәләсе буенча үзенең вәкаләтләренең бер өлешен атарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә тапшыра:**

- «Новопольский» авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең Новопольский п. Ирек урамы буенча автомобиль юлын ремонтлау.